# «Лә иләһә илләЛлаһ» кәлимәсенең шартлары

## شروط لا إله إلا الله

اللغة التتارية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

ALSARHAAN.COM
Mahadsunnah.com

Сорау: «Лә иләһә илләЛлаһ» кәлимәсенең нинди шартлары бар?
Җавап: җиде шарт.

Беренчесе – наданлыкка капма-каршы булган гыйлем, һәм ул үз эченә исбат итүне һәм инкарь итүне ала.
Аллаһ әйтте: «Бел, Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк...».
Гөсмәннән (Аллаһ аннан риза булсын) хәбәр ителә: "Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Кем дә кем «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк» икәненә инанып үлсә, шул Җәннәткә керәчәк".

Икенчесе – бу кәлимәнең мәгънәсенә ныклы ышану ягъни шикләнмәү.
Хакыйкатьтә, иман – ныклы ышану ул, чамалау түгел.
Аллаһ әйтте: «Мөэминнәр – ул Аллаһка һәм Аның Расуленә иман китергәннәре, шуннан соң шикләнмәгәннәре, җаннары һәм үз мал-мөлкәтләре белән җиһат кылганнары, менә шулар ул хак иман китерүчеләр».

һәм бу шарт Аллаһка һәм Аның расуленә чын-чынлап иман китерү һәм соңыннан шикләнмәү шарты белән чикләнә.

Әбү Хурайрадан (Аллаһ аннан риза булсын) хәбәр ителә: "Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Мин Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк һәм мин Аның Расуле икәненә шаһәдәт китерәм, һәм Аллаһ Үз бәндәсен шушы ике кәлимәдә шикләнмәгән килеш очратса, ул Җәннәткә керәчәк".

Өченчесе — шушы кәлимә бездән таләп иткән нәрсәне йөрәк һәм тел белән кабул итү.

Аллаһ безгә элек булган хәбәр турында, ягъни бу кәлимәне кабул иткәннәрне коткаруы, ә кире каккан һәм тәкәбберләнгәннәрдән үч алуы турында хикәя кылды.

Дүртенчесе — шушы кәлимәгә каршы килә торган нәрсәләрне калдыруда буйсыну.
Аллаһ әйтте: «Кем дә кем үзен вә бөтен эшен Аллаһка тапшырса вә шул эшен никадәр яхшы кылса, ул кеше ныклы арканга ябышты».
Ягъни «Лә иләһә илләЛлаһ» кәлимәсенә.
Һәм «үзен тапшырды» - дигән сүзләрнең мәгънәсе — Бер Аллаһка инанган, игелекле эшләр кылган килеш буйсыну, ә кем үзен Аллаһка тапшырмаса, хәерле гамәлләр кылмаса, ул ныклы арканга тотынмаган булып чыга.
Аллаһ әйтте: «Кем дә кем көферлек китерсә, аның көферлеге сине көендермәсен, аларның кайтачаклары Безгәдер, кылган эшләреннән үзләренә белдерербез». ( Локман сүрәсе, 23 аять).

Бишенчесе — ялганга капма-каршы булган турылык.

Ягъни бу кәлимәне турылыклы хәлдә йөрәгеңнән чыгып әйтү. Йөрәкнең тел белән ризалашуы. Бөек Аллаһ әйтте: «Әллә кешеләр "иман китердек" дигәч сыналмаслар дип уйладыlармы, чынлыкта, алардан алда булганнарны да сынадык Без, һичшиксез Аллаһ үз иманнарында дөрес булучыларны һәм ялганчыларны беләчәк».

Мүгәз ибн Җәбәлдән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителә: "Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Кем дә кем Аллаһтан башка гыйбадәт кылырлык хак илаһи зат юклыгына һәм Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе икәнлегенә йөрәгендә тугрылыклы килеш шаһәдәт китерә икән, Аллаһ аңа Җәһәннәм утын хәрам кылачак".

Алтынчысы — ихласлык, һәм ул — гамәлләребезне барлык ширек катышмасыннан пакьлау.
Аллаһ әйтте: «Ширектән пакь булган дин Аллаһка хас түгелме?»
Әбү Хурайрадан хәбәр итеслә: "Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "«Лә иләһә илләЛлаһ» кәлимәсен ихлас күңелдән әйткәне — минем шәфәгатемә кешеләрдән иң лаеклысы".

Җиденчесе — бу кәлимәгә һәм ул таләп иткән нәрсәләргә карата, аны әйткән һәм аның белән гамәл иткән, аның шартларын үтәгән кешеләргә карата мәхәббәт һәм аңа капма-каршы булган нәрсәләргә карата нәфрәт хисен кичерү.
Аллаһ әйтте: «Кешеләр арасында шундыйлары бардыр, кем Аллаһтан башкаларны Аллаһка тиңдәш итеп алып, аларны Аллаһны сөйгән кебек сөя. Әмма Аллаһка иман китерүчеләр Аллаһны катырак сөю белән сөяләр».

Әнәстән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр итеолә: "Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Мине үз атасыннан, баласыннан яки барлык кешеләрдән күбрәк яраткачыга хәтле сездән берегез дә чын-чынлап иман китермәс".

Аллаһ белүчерәк.